РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН СОВЕТ
БИК-УТЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БИК-ҮТИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

21 гыйнвар 2021 ел № 1-11

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районы Бик-Үти авыл җирлегендә
бюджет процессы турындагы нигезләмәгә
үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Бик-Үти авыл җирлеге

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Бик-Үти авыл җирлегенең 2018 елның 14 июлендәге 51-2 номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Бик-Үти авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында карары белән расланган (12.05.2020 елның 84 номерлы, 19.08.2020 елның 90-2 номерлы, 20.10.2020 елның 2-4 номерлы карарлар редакциясендә) Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Бик-Үти авыл җирлегендә бюджет процессы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 6 статьяның 2 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

1.2. 31 статья:

1 пунктның 2 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Казна учреждениесенең бюджет сметасы Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән гомуми таләпләр нигезендә бюджет акчаларының баш күрсәтмәсендә билгеләнгән тәртиптә төзелә, раслана һәм алып барыла..»;

1.3. 33 статьяның 2 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Максатчан билгеләнеше (аларны бирү турында хәбәрнамә алган очракта), шул исәптән әлеге Кодексның 242 статьясындагы 5 пунктында билгеләнгән тәртиптә бюджетка керә торган субсидияләр, субвенцияләр, башка бюджетара трансфертлар, шулай ук бюджетны үтәгәндә законда (карар) расланган керемнәр бюджеты турында карар) расланган физик һәм юридик затлардан фактта кире кайтарылмый торган кертемнәр күрсәтелгән акчаларны бирү максатларына туры килә торган бюджет чыгымнарын арттыруга, агымдагы финанс елына (агымдагы финанс елына һәм план чорына) бюджет турындагы канунга (карарга) үзгәрешләр кертмичә, җыелма бюджет язуына үзгәрешләр кертеп, юллана.».

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча басылып чыккан көненнән закон көченә керә, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

4. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

ТР Буа муниципаль районының
Бик-Үти авыл җирлеге башлыгы Р.З. Залялетдинов